РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ ГОРОДА КУКМОР
422110, г. Кукмор, ул. Ленина, 15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ
422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15

РЕШЕНИЕ КАРАР

14 март, 2025 ел № 4

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Кукмара шәһәре Советы карары проекты хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезләмәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Кукмара шәһәре Советы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Кукмара шәһәре Советы карары проектын хупларга (1 нче кушымта).

2. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 17 февралендәге 5 номерлы Кукмара шәһәре Советы карары нигезендә «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Кукмара шәһәре Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрергә.

3. «Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү һәм аның буенча фикер алышуда гражданнарның катнашуы турында» Кукмара шәһәр Советы карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен расларга (2 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү проекты буенча кергән

тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

Аксанова А.Р. – комиссия рәисе;

Андреев В.Н. – комиссия рәисе урынбасары;

Сабирова М.Ф. – комиссия әгъзасы;

Орехов А.В. – комиссия әгъзасы;

Юртаева Р.М. – комиссия әгъзасы.

5. Билгеләргә:

5.1. Гавами тыңлауларны үткәрү датасы – 2025 елның 7 апреле.

5.2. Гавами тыңлауларны үткәрү вакыты – 18.00 сәгать.

5.3. Үткәрү урыны – Кукмара шәһәре Башкарма комитеты, адресы: ТР, Кукмара районы, Ленин урамы, 15 нче йорт.

6. Эшче төркемгә ачык тыңлауларда кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Советы утырышына карарга кертергә.

7. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Интернет челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында http://kukmor.tatar.ruурнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Кукмара шәһәре мэры С.Д. Димитриев

Кукмара шәһәре Советының 2025
елның 14 мартындагы 4 номерлы
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
Кукмара шәһәре Советы

КАРАР

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә муниципаль берәмлек Уставы нигезләмәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Кукмара шәһәре Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль берәмлекнең рәсми атамасы – Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге, кыскартылган исеме-Кукмара шәһәре (алга таба текст буенча - җирлек).».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Кукмара шәһәре мэры С.Д. Димитриев

Кукмара шәһәре Советының 2025 елның 14 мартындагы 4 номерлы карарына 2 нче кушымта

«Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Кукмара шәһәр Советы карары проектына гражданнар тәкъдимнәрен һәм һәм аның турында фикер алышуда гражданнарның катнашуын исәпкә алу тәртибе

1. «Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проектына тәкъдимнәр Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре Советына кертелә адресы: Кукмара ш., Ленин ур., 15 й. яисә факс белән (84364) 2-63-04 кушымта итеп бирелгән үрнәк буенча төзәтмәләр таблицасы рәвешендә язма формада:

| т/б № | Статья, пункт, пунктча | Карар проекты тексты | Төзәтмә тексты | Төзәтмәләрне исәпкә алып, проект тексты | Төзәтмә авторы (Ф.И.А, адресы, телефоны, эш (уку) урыны |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр эш көннәрендә 8 сәгать 00 минуттан 17 сәгатькә кадәр карар игълан ителгән көннән бер ай эчендәкабул ителә.

2. Гавами тыңлауларда чыгыш ясау хокукы белән катнашу өчен гаризалар шәхсән яки почта аша: 422110, Кукмара ш., Ленин ур., 15 йорт (конвертта «Устав турында фикер алышу» яки «гавами тыңлаулар» дигән тамга белән), шулай ук факс буенча (84364) 2-63-04 тапшырыла.

Гаризалар гавами тыңлаулар үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча, эш көннәрендә 8 сәгать 00 минуттан 17 сәгатькә кадәр кабул ителә.

3. Гражданнарның тәкъдимнәре Кукмара шәһәре Башкарма комитеты хезмәткәрләре тарафыннан теркәлә һәм карау өчен Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Советы рәисе урынбасарына тапшырыла.

Кукмара шәһәре мэры С.Д. Димитриев